СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная Площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 27.07.2026 | с. Коргуза | 9-51 |

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-4

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советының 29.03.2013 ел № 31-143 карары белән (27.05.2021 ел № 9-56 карары үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы

карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә, «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 22 нче филиалы Патрикеево авыл клубын бетерү мәсьәләсе буенча халык фикерен ачыклау максатында, исемле тавыш бирү рәвешендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләргә.
2. Билгеләргә:
   - сораштыруны үткәрү датасы һәм вакыты - 07.08.2026 ел 8.00 дән 20.00 гә кадәр;
   - сораштыру үткәрү урыны - гражданнарны теркәү урыны буенча.
3. Сораштыру исемлекләре буенча исемләп тавыш бирү үткәрергә
4. Гражданнардан сораштыру үткәргәндә сораштыру исемлегенә кертү өчен түбәндәге сорауның формулировкасын расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 22 нче филиалы Патрикеево авыл клубын бетерүгә ризамы?"
5. Сораштыру үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
6. Сораштыру исемлегенең формасын һәм текстын расларга (2 нче кушымта).
7. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегендә 255 кешедән торган сораштыруда катнашучыларның минималь санын билгеләргә.

8. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов

Карагуҗа авыл җирлеге Советының
27.07.2026 ел № 9-51 карарына
1 нче кушымта

Гражданнардан сораштыру үткәрү

КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

1. Плохов Д.В. - Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы
2.Турицина С.И. - Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре
3. Грачева Л.В. - Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында яшәүче
4. Тарасова Л.А.- Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылында яшәүче
5. Абызова Г.А. - Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылында яшәүче

Карагуҗа авыл җирлеге Советының
27.07.2026 ел № 9-51 карарына
2 нче кушымта

СОРАШТЫРУ ИСЕМЛЕГЕ

Сораштыру үткәрелә торган сорауны формулировкалау: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 22 нче филиалы Патрикеево авыл клубын бетерүгә ризамы?"

| Фамилия, исеме, атасы исеме | Туган көне, ае һәм елы | Яшәү урынының адресы | Дата | Тавыш бирү тамгасы | | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | РИЗА | КАРШЫ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |

Комиссия рәисе________________________________ ________________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)

Комиссия секретаре ______________ ________________ ________________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)